**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 июль 2014 ел Казан шәһәре № 9-1/нпс

***Татарстан Республикасы җирендә урнашкан җир бүлемтекләренә карата кадастр эшләрен алып баруга максималь чик бәяләрне билгеләү турында***

“Күчемсез милек дәүләт кадастры турында” 24.07.2007 № 221-ФЗ Федераль законы нигезендә, 15 июнь, 2010 ел, №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы җирендә урнашкан җир бүлемтекләренә карата кадастр эшләрен алып баруга максималь чик бәяләрне, әлеге карарның кушымтасына килештереп билгеләргә.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип исәпләргә:

“Татарстан Республикасы җирендә урнашкан җир бүлемтекләренә карата кадастр эшләрен алып баруга максималь чик бәяләрне билгеләү турында” 18.12.2009 № 9-10/нпс Татарстан Республикасы тарифлар буенча дәүләт комитеты Идарәсе карарын;

“Татарстан Республикасы җирендә урнашкан җир бүлемтекләренә карата кадастр эшләрен алып баруга максималь чик бәяләрне билгеләү турында” 18.12.2009 № 9-10/нпс Татарстан Республикасы тарифлар буенча дәүләт комитеты Идарәсе карарына үзгәрешләр кертү турында” 10.02.2012 № 9-1/нпс Татарстан Республикасы тарифлар буенча дәүләт комитеты карарын.

3. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
кушымта
18 июль 2014 ел № 9-1/нпс

Татарстан Республикасы җирендә урнашкан
җир бүлемтекләренә карата кадастр эшләрен алып баруга
максималь чик бәяләр

Бәяләр сумнарда ӨБС исәпкә алынган

| № п/п | Түбәндәгеләр өчен атап куелган | Шәһәр торак пунктларында | Авыл торак пунктлары | Торак пунктлары чикләреннән тыш |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып бару | 4898 | 4181 | 5328 |
| 2. | Индивидуаль торак төзелеше | 4898 | 4181 | 5328 |
| 3. | Индивидуаль гаражлар төзү | 4377 | 3621 | 4756 |
| 4. | Бакчачылык, дача хуҗалыгы | 4693 | 3874 | 5103 |

Искәрмә.

1. Татарстан Республикасы җирендә кадастр эшләрен алып баручы барлык юридик затлар тарафыннан, шәхси эшмәкәр һәм оештыру-хокук формасына бәйсез хәлдә максималь тарифлар кулланыла.
2. Бәяләр чик бәяләр булып тора һәм кадастр эшләрен алып баручы юридик зат яисә шәхси эшмәкәр карамагына карап төшерелергә мөмкин.
3. Кадастр эшләренә максималь чик бәяләр бер җир бүлемтегенә исәпләнгән һәм гражданнар кадастр эшләре өчен түләгәндә кулланыла.
4. Кадастр эшләренең нәтиҗәсе булып межа планы тора.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге